КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 ноябрь г.Казань № 1531

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турында» 2008 ел, 28 март, 206 нчы карары белән расланган Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турында» 2008 ел, 28 март, 206 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 7 сентябрь, 717 нче; 2011 ел, 21 июнь, 497 нче; 2012 ел, 17 июль, 610 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 33 нче; 2023 ел, 18 март, 274 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина

иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «ТР ИСТҮ» ДБУ) түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертә:»;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

«$11^1$. Бюджетны планлаштыру субъектлары, «ТР ИСТҮ» ДБУ агымдагы финанс елының 15 июненә кадәр башлангыч мәгълүматны булдыру һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертларның исәп-хисапларын ясау өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына мәгълүмат тапшыра.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы башлангыч мәгълүматны булдыру һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертларның исәп-хисапларын ясау өчен агымдагы финанс елның 15 июненә кадәр мәгълүмат бирү турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына рәсми сорау җибәрә.

Бюджет планлаштыру субъектлары агымдагы финанс елның 15 июненә кадәр, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектына тиешле кушымталарны булдыру өчен исәп-хисапларны теркәп, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары арасында бюджетара трансфертларны бүлү методикаларын (методикалары проектларын) һәм проектларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертә.»;

29 пунктның «б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин